РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» ноябрь 2021 ел г. Альметьевск № 1613

Әлмәт муниципаль районы Башкарма
комитетының кайбер карарлары
үз көчен югалткан дип тану турында

Муниципаль хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарларын юкка чыгарырга:

«Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 28 декабрендәге 2290 номерлы;

«Опекага алынган бала мөлкәте белән алыш-бирешләр кылуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 04 октябрендәге 1778 номерлы;

«Опекага алынган баланың үз карамагындагы торак тапшыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 02 декабрендәге 2096 номерлы;

«Опекага алынган бала мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсен төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 27 сентябрендәге 1738 номерлы;

«Опекага алынган баланың саклык счетыннан файдалануга опекунга яисә попечительгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 20 ноябрендәге 2012 номерлы

«Опекунга яисә попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 18 ноябрендәге 2005 номерлы;

«Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма

Зак. № 305-2000

комитетының 2018 елның 28 декабрендәге 2290 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 июлендәге 1013 номерлы.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы О.Н. Шабалин

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ